| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |
|---|---|

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

23.03.2016　　　　　Казан шәһәре　　　　　01-05/76-пр

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәтенең аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан чит илләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы яисә махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 10 октябрендәге № 506 Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан чит илләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 12 гыйнварындагы № УП-5 Указы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең

мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу буенча кушымта итеп бирелүче тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Оештыру-хокукый эш бүлеге башлыгы (Аблиева Л.М.) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре белән хезмәт контрактлары төзегәндә әлеге боерык белән аларны таныштыруны;

Тәртипне Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең «Коррупциягә каршы сәясәт» мәгълүмат стендында урнаштыруны.

3. Күзәтчелек һәм автоматлаштырылган исәпкә алу бүлеге (Хәйруллин Р.Ф.) әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштырырга тиеш.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык вазыйфаларын вакытлыча башкаручы М.А. Халиков

Татарстан Республикасы
Үзйөрешле машиналар һәм
башка төр техниканың техник
торышына күзәтчелек идарәсенең
23.03.2016 № 01-05/76-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибе

Әлеге Тәртип белән, әгәр граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларына шушы оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек кермәсә, Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – граждан хезмәткәре, Идарә) тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләкләүләрен (алга таба – исемнәр, бүләкләүләр) кабул итеп алу процедурасы регламентлана.

2. Граждан хезмәткәре исемнәр, бүләкләүләр алганда Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе башлыгыннан (алга таба – башлык) рөхсәт алырга тиеш

3. Чит дәүләттән, халыкара оешмадан, сәяси партиядән, башка иҗтимагый берләшмәдән, дини берләшмәдән исем, бүләкләү алган йә аларны алачагы турында хәбәрнамә алган граждан хезмәткәре, чит дәүләттән, халыкара оешмадан, сәяси партиядән, башка иҗтимагый берләшмәдән, дини берләшмәдән мактаулы яисә махсус исем алуга рөхсәт сорап, өч эш көне эчендә оештыру-хокукый эш бүлегенә әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча үтенечнамә (алга таба – үтенечнамә) тапшыра.

Үтенечнамәне карау срогы оештыру-хокукый эш бүлеге тарафыннан әлеге Тәртипнең 8 пункты нигезендә үтенечнамә теркәлгән көннән ун эш көне тәшкил итә.

4. Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы исеменнән, бүләкләүдән баш тарткан граждан хезмәткәре мактаулы яисә махсус исемен, бүләкләвен алудан баш тартуы турында әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча төзелгән хәбәрнамәне (алга таба – хәбәрнамә) өч эш көне эчендә оештыру-хокукый эш бүлегенә тапшыра.

5. Башлык исем, бүләкләү алган граждан хезмәткәренең үтенечнамәсен карау нәтиҗәләре буенча карар кабул иткәнче, исемгә, бүләкләүгә документларның төп нөсхәләрен һәм аларга кушып бирелүче документларның төп нөсхәләрен, аларны алганнан соң өч эш көне эчендә, оештыру-хокукый эш бүлегенә җаваплы саклауга

тапшыра. Бу чакта әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча тапшыру-кабул итеп алу акты төзелә.

6. Граждан хезмәткәре хезмәт командировкасы вакытында исем, бүләкләү алганчы ук алардан баш тарткан очракта, үтенечнамәне тапшыру срогы граждан хезмәткәре хезмәт командировкасыннан кайткан көннән алып исәпләнә башлый.

7. Граждан хезмәткәре үзенә бәйле булмаган сәбәп аркасында үтенечнамәне яисә хәбәрнамәне, исемгә, бүләкләүгә документларның төп нөсхәләрен һәм аларга кушып бирелүче документларның төп нөсхәләрен әлеге Тәртипнең 3 – 5 пунктларында күрсәтелгән срокта тапшыра алмаган очракта, ул үтенечнамәне яисә хәбәрнамәне, исемгә, бүләкләүгә документларның төп нөсхәләрен һәм аларга кушып бирелүче документларның төп нөсхәләрен бу сәбәпне бетергәннән соң килүче эш көне эчендә тапшырырга тиеш.

8. Үтенечнамәне (хәбәрнамәне) теркәү оештыру-хокукый бүлек тарафыннан үтенечнамә (хәбәрнамә) теркәү журналына кертелгән көнне әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча гамәлгә ашырыла. Теркәлгән үтенечнамәне (хәбәрнамәне) оештыру-хокукый эш бүлеге ике эш көне эчендә башлык каравына җибәрә.

9. Оештыру-хокукый эш бүлеге ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә үтенечнамәне карау нәтиҗәләре буенча башлык кабул иткән карар турында хәбәр итә һәм аңа оештыру-хокукый эш бүлеге мөһере белән таныкланган һәм башлык резолюциясе куелган үтенечнамә (хәбәрнамә) күчермәсен имза салдырып бирә. Үтенечнамәнең (хәбәрнамәнең) төп нөсхәсе башлык резолюциясе белән граждан хезмәткәрнең шәхси эш кәгазьләренә беркетеп куела.

10. Башлык граждан хезмәткәренең әлеге Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән үтенечнамәсен канәгатьләндергән очракта, оештыру-хокукый эш бүлеге 10 эш көне эчендә граждан хезмәткәренә исемгә, бүләкләүгә документларның төп нөсхәләрен һәм аларга кушып бирелүче документларның төп нөсхәләрен тапшыра. Бу чакта әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча кабул итеп алу-тапшыру турында акт төзелә.

11. Башлык граждан хезмәткәренең әлеге Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән үтенечнамәсен канәгатьләндерүдән баш тарткан очракта, оештыру-хокукый эш бүлеге 10 эш көне эчендә исемгә, бүләкләүгә документларның төп нөсхәләрен һәм аларга кушып бирелүче документларның төп нөсхәләрен чит дәүләтнең тиешле органына, халыкара оешмага, сәяси партиягә, башка иҗтимагый берләшмәгә, дини берләшмәгә җибәрә.

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибенә

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе башлыгына

________________________________________

__________________________

________________________________________

__________________________

_________________________________

(Ф.Ис.Ат. ис., биләүче вазыйфасы)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең һәм дини берләшмәнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алуга рөхсәт турында
үтенечнамә

Миңа
________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________

(мактаулы яисә махсус исем, бүләкләү атамасы)

кабул итеп алырга рөхсәт итүегезне үтенәм
________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

____________________________________________________________ (нинди казанышлары өчен һәм кем тарафыннан бирелгән, нинди казанышлары өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнгән)

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
______________________________________________________
(мактаулы яисә махсус исемгә, бүләкләүгә документлар тапшыру датасы һәм урыны)

Мактаулы яисә махсус исемгә, бүләкләүгә документлар һәм аларга кушып бирелүче документлар
(кирәклесенең астына сызарга)

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
______________________________________________________
(мактаулы яисә махсус исем, бүләкләү атамасы)

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
______________________________________________
(мактаулы яисә махсус исемгә, бүләкләүгә документлар атамасы)

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең оештыру-хокукый эш бүлегенә 20__ елның «___» № кабул итеп алу-тапшыру акты буенча тапшырылган

20 ___ елның « »____________________ _______________
(датасы) (имзасы)

______________________________________ (имза расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибенә

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе башлыгына
________________________________________
__________________________
________________________________________
__________________________
_________________________________
(Ф.Ис.Ат.ис., биләүче вазыйфасы)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең,
башка иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы яисә махсус исемен,
бүләкләвен кабул итеп алудан баш тарту турында
хәбәрнамә

____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
________________________________________________ (мактаулы яисә махсус исем, бүләкләү атамасы)

алудан баш тартуым турында үзем кабул иткән карар турында хәбәр итәм
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
_______________________________________________

(нинди казанышлары өчен һәм кем тарафыннан бирелгән, нинди казанышлары өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнгән)

20 __елның « »

______________________________ (датасы)

______________________________ (имзасы)

______________________________ (имза расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибенә

3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе башлыгына
_______________________________________
__________________________
_______________________________________
__________________________
________________________________
(Ф.Ис.Ат.ис., биләүче вазыйфасы)

Кабул итеп алу-тапшыру актысы

20__ елның «___» ____________ № __________

Без, түбәндә имза салучылар,______________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________турында акт төзедек,
(Ф.Ис.Ат. ис., вазыйфасы) тапшырды/кабул итеп алды (кирәклесенең астына сызарга) ә Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек башлыгы оештыру-хокукый эш бүлеге
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
_________________________________________________________
(Ф.Ис.Ат. ис.) түбәндәгеләрне кабул итеп алды/тапшырды (кирәклесенең астына сызарга):

| № т/н | Атамасы | Саны (данә) | Тасвирламасы |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Тапшырды ________________ Кабул итеп алды _______________________
(имзасы) (имзасы)

______________________________ ___________________________
(имза расшифровкасы) (имза расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибенә

4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе башлыгына
_______________________________________
__________________________
_______________________________________
__________________________
________________________________
(Ф.Ис.Ат. ис., биләүче вазыйфасы)

Үтенечнамәләрне
(хәбәрнамәләрне) исәпкә алу
ЖУРНАЛЫ

| № | Үтенеч-намә (хәбәрнамә) тапшыр-ган граждан хезмәт-каре Ф.Ис.Ат.ис. | Үтенеч-намә (хәбәрна-мә) тапшыр-ган граждан хезмәт-каре вазыйфа-сы | Үтенеч-намә (хәбәр-намә) керү датасы | Бүләк-ләү, исем атамасы | Кабул итеп алу-тапшыру акты рекви-зит-лары (бул-са) | Үтенеч-намә (хәбәр-намә) кабул итеп алган зат имзасы, Ф.Ис. Ат. ис. | Үтенеч-намә (хәбәр-намә) тапшыр-ган зат имзасы, Ф.Ис. Ат. ис.) | Рәис карары турын-да мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |